# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Алексеевск шәһәр җирлеге составына керүче
Сабакайка авылы торак пунктында

2020 елның 24 ноябре

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге составына керүче Сабакайка торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда Сабакайка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан, тәрбиясендә 18 яшькә кадәрге 3 баласы булган гаиләләрдән тыш, гражданнарның үзара салымын 500 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү:
   - авыл эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту;
   - балалар өчен уен мәйданчыклары сатып алу һәм урнаштыру;
   - урамнарны һәм ял зоналарын төзекләндерү һәм яшелләндерү;
   - һәйкәлләрне төзү һәм төзекләндерү;
   - җирләү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү;
   - суүткәргеч һәм канализация челтәрләрен төзү һәм реконструкцияләү.
3. Әлеге карарны Җирлекнең рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары В.В. Увакинага йөкләргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Аексеевск шәһәр җирлеге башлыгы С.А. Демидов